| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2015 ел Казан ш. № 5-64/тэ

2016 елда кулланучыларга һәм башка җылылык белән тәэмин ителүче оешмаларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар биргән җылылык энергиясенә тарифлар билгеләү турында

2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы 190-ФЗ федераль законга ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында»гы 1075нче карары белән, Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә көйләнгән бәяләрне (тарифлар) исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында»гы 760-э әмере, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Казан шәһәрен 2029 елга кадәр җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында»гы 2015 елның 13нче мартындагы 130нчы боерыгы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендә 468нче карары белән расланган. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты Положениесе белән, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасы турында»гы 2014 елның 21 августындагы 30-1нче карары белән Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2016 елда кулланучыларга һәм башка җылылык белән тәэмин ителүче оешмаларга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар биргән җылылык энергиясенә тарифларны әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә календарь вакытка бүлеп билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2016 елның 1 гыйнварыннан алып 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң 10 көн дәвамында үз көченә кертелә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 16.12.2015 № 5-64/тэ
карарына кушымта

# 2016 елда җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин ителүче оешмаларга календарь вакытка бүлеп бирүче җылылык энергиясенә (егәрлек) тарифлар

| № п/п | Оешма тарафыннан көйләнгән муниципаль берәмлек исеме, тариф төре | Ел | Су | Басым астындагы пар | | | | Кискен һәм кыскартылган пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2дән 2,5кә кг/см$^2$ | 2,5 дән 7,0гә кг/см$^2$ | 7,0 дән 13,0кә кг/см$^2$ | 13,0тән югарырак кг/см$^2$ | |
| | Арча муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Таткоммунэнерго» Акционерлык җәмгыяте Республика җитештерү берләшмәсе» | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, кабызу схемасы буенча дифференциацияләнгән тарифлар булмаган очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, руб./Гкал | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 1330,10 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | 1388,68 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (НДС кертелгән тарифлар)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, руб./Гкал | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 1569,52 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | 1638,64 | - | - | - | - | - |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 2 | «Таткоммунэнерго» Акционерлык җәмгыяте Республика җитештерү берләшмәсе» | | | | | | | |
| 2.1 | Кулланучылар өчен, кабызу схемасы буенча дифференциацияләнгән тарифлар булмаган очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, руб./Гкал | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 1097,49 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | 1181,73 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым Кодексыныж 168нче маддәсенең 6нчы пунктын гамәлгә ашыру өчен билгеләнә

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге